# ЯХЪЯДАН ИКЕНЧЕ ХАТ

[1] Аксакалдан – Аллаһы тарафыннан сайланган ханымга һәм
аның балаларына. Мин һәммәгезне ихлас күңелдән яратам.
Һәм мин генә түгел, бәлки хакыйкатьне танучы һәммә кеше
сезне ярата. [2] Без сезне яратабыз, чөнки хакыйкать бездә тора
һәм безнең белән мәңге булачак.

[3] Аллаһы Атадан һәм Атаның Улыннан – Гайсә Мәсихтән
бирелгән мәрхәмәт, шәфкать һәм иминлек безнең белән хакыйкатьтә һәм мәхәббәттә булсын.

*Хакыйкать һәм мәхәббәт*

[4] Синең балаларың арасында без Атадан кабул иткән әмер
буенча хакыйкатьтә йөрүчеләрне тапканыма бик сөендем. [5] Хә-
зер, ханым, сиңа яңа әмер түгел, бәлки баштан ук без кабул
иткән әмерне язам һәм үтенәм: бер-беребезне яратыйк. [6] Мә-
хәббәт исә шуннан гыйбарәт: без Аллаһының әмерләре буенча
йөрергә тиешбез. Сез баштан ук ишеткәнегезчә, Аның әмере
шуннан гыйбарәт: сез мәхәббәттә яшәргә тиешсез.

[7] Гайсә Мәсихнең тәндә килүен инкяр итүче күп ялганчылар дөньяга чыктылар. Андый кешеләр – ялганчылар һәм Мә-
сих дошманнары. [8] Сез нәрсә хакына эшләгәнебезне югалтмас
өчен, бәлки тулы әҗер алыр өчен, сак булыгыз. [9] Мәсих тәгъ-
лиматын сакламаган һәм аның чигеннән узган һәркемдә Аллаһы юктыр. Тәгълиматны саклаучыда исә Ата да, Аның Улы да
бар. [10] Әгәр сезгә берәү килсә һәм бу тәгълиматка өйрәтмәсә, ул
кешене өегездә кабул итмәгез һәм аны сәламләмәгез. [11] Чөнки
сәламләгән кеше аның явыз эшләренә кушыла.

[12] Сезгә яза торган сүзләрем күп, әмма кәгазьгә кара белән
язарга теләмим, бәлки куанычыбыз тулы булсын өчен, яныгызга килеп, сезнең белән сөйләшергә өметләнәм.

[13] Аллаһы тарафыннан сайланган имандаш кыз туганыңның
балалары сине сәламлиләр.